Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Күн авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

11 февраль, 2026 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч районының Күн авылында урнашкан җир кишәрлеге территориясен планлаштыру проектын раслау буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 63 номерлы карары белән расланган нигезләмә (2017 елның 13 декабрендәге 78 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 90, 2019 елның 20 сентябрендәге 133 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 58 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 65 номерлы үзгәрешләре белән) нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Күн авылы территориясенең бер өлешен планлаштыру проекты (кадастр номерлары 16:33:040422:354, 16:33:040422:352 булган җир кишәрлекләре) ( алга таба-проектлана торган объект, территорияне планлаштыру буенча документлар).

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 27 февраленнән дә соңга калмыйча тәгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов